**ГЛАВА**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «22» маеннан № 19

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы иҗтимагый советы составының өчтән бер өлешен раслау турында

«Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектлары иҗтимагый палаталарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2016 елның 23 июнендәге 183-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җәмәгать контролен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2017 елның 20 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында иҗтимагый советы турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2024 елның 19 апрелендәге 45-343 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы иҗтимагый советы составының өчтән берен кушымта нигезендз расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан

Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Башлык В.М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгының
2024 елның «22» маеннан
19 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы иҗтимагый советы составының өчтән бер өлеше исемлеге

1. Ерохина Валентина Вячеславовна – Татарстан Республикасы мәдәният хезмәткәрләренең Яңа Чишмә район профсоюз оешмасы рәисе (килешү буенча);
2. Мәхмүтова Эльвира Эдуард кызы - «Татарстан - новый век» - «Татарстан - яңа гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәтенең Яңа Чишмә территориаль бүлеге советы рәисе (килешү буенча);
3. Михеева Любовь Васильевна – «Татарстан Республикасы рус милли-мәдәни берләшмәсе» региональ иҗтимагый оешмасының Яңа Чишмә бүлекчәсе Советы рәисе (килешү буенча);
4. Селиверстова Дарья Михайловна – «Бердәм Россия Яшь гвардиясе» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсенең Яңа Чишмә җирле бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча).